Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

16 ноябрь 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында” гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 16 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Кама-Елга авылында урам утлары челтәрен норматив хәлгә китерүгә, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләү өчен тоту?” мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев